
# Җирле сөйләшләрдә милли менталитетның чагылышы





“Без – татарлар, телебез – татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул.”

Каюм Насыйри

- Милләт – менталитетлары уртак булган, милли үзаңлы һәм характерлы, милли мәдәниятнең тотрыклы сыйфатларына ия, башка халыклар белән охшашлыкны һәм алардан аерымлылыкны аңлаучы кешеләрнең тарихи үсеше нәтиҗәсендә барлыкка килгән бергәлек ул.

- Тел һәм милләт – теләсә кайсы милләтнең аерымлылык билгеләре. Милли телдә халыкның менталитеты, культурасы, тарихы чагыла. Туган тел милли әдәбият , сәнгать, музыка, халык аваз иҗаты белән тыгыз бәйләнештә.

Милләтнең менталитеты түбәндәгеләрдә дә чагылыш таба:

- милләт вәкилләренең хезмәткә мөнәсәбәте, хезмәт эшчәнлеге белән бәйле традицияләре;
- тормыш- көнкүреш уңайлыклары турындагы күзаллаулар;
- матурлык, гүзәллек идеаллары;
- яхшылык, ягымлылык, чама хисен белү кебек сыйфатларны аңлау үзенчәлекләре һ.б.

- Диалект – гомумхалык теленең аерым бер җирлеккә хас төре. Аның үз аваз составы , грамматикасы бар;  ул сөйләмә формада яши.

- Тел һәм мәдәният – теләсә касы милләтнең аерымлылык билгесе. Туган тел милли әдәбият, сәнгать, музыка , халык иҗаты белән тыгыз бәйләнештә. Шуңа күрә барлык халыклар аны белем һәм тәрбия бирүнең әһәмиятле чарасы дип саный.

- Без - укучыларның әдәби тел формалаштыруында укытучыларыбызның татар теле һәм әдәбияты дәресләрен хәзерге әдәби телдә оештыруы безнең телебезне әдәби телгә якынайта, сөйләмебезне төзек, камил һәм грамматалы итеп формалаштырырга ярдәм итә.